**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**9 октябрь, 2021ел** **№ 111**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы рәисе-Башлыгы Р.Г. Кәлимуллинның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 6 өлешенең 2 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясының 8 өлеше, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставының 45 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Кәлимуллин Рөстәм Галиулловичның Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы рәисе – Башлыгы вазыйфасыннан үз теләге белән шәхси гаризасы нигезендә отставкасын кабул итәргә.

2. «Единая Россия» бөтенроссия сәяси партиясе тарафыннан күрсәтелгән кандидатларның федераль исемлеге составында Дәүләт Думасы Федераль Собраниесе VIII чакырылыш депутаты итеп сайлануы белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы рәисе – Башлыгы Кәлимуллин Рөстәм Галиулловичның вәкаләтләрен 2021 елның 9 октябреннән вакытыннан алда туктатырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисенең урынбасары,
муниципаль район башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров